**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 елның 13 феврале № 123

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында»гы 2023 елның 16 гыйнварындагы 117 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2023 елның 16 гыйнварындагы 117 номерлы «2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында» карарының 1 пунктында «эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**